ГЛАВА ТАШКИЧУЙСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ЮТАЗИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Советская, д.18а, д.Малые
Уруссу, 423959

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ ТАШКИЧҮ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Совет урамы, 18а йорт, Кече Урыссу
авылы., 423959

Тел.:(85593) 4-23-10, факс:4-23-40, e-mail: Tash.UTz@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

***№ 3*** **«17» сентября 2020г**

2020 елның 3 июнендәге Ташкичү авыл җирлеге башлыгының 2 санлы карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибе турында»

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 131-ФЗ санлы, 2006 елның 2 маендагы «Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 59-ФЗ санлы Федераль законнар, 2003 елның 12 маендагы «Татарстан Республикасында гражданнар мөрәҗәгатьләре турында» 16-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә

карар бирәм:

1.2020 елның 3 июнендәге Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге башлыгының 2 санлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Ташкичү авыл җирлеге җирле үзидарә органнарына гражданнардан кергән мөрәҗәгатьләргә анализ үткәрү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

- 4 бүлектә «ел саен» сүзен «һәрдаим» (әмма елына бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә) дип алмаштырырга;

- 5 һәм 8 бүлекләрдә «хисап чорыннан соң килүче» сүзләрен «киләсе хисап елы» дигән сүзләргә алмаштырырга.

2. Әлеге карарны Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен үз контролемдә тотам.

Ташкичү авыл җирлеге башлыгы Р.К. Вәлиев